**ГЛАВА УРАХЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422661, Республика Татарстан, Рыбно-Слободский район, с.Урахча, ул.Советская, дом 36а**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ УРАКЧА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**422661,Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Уракчы авылы, Совет урамы, 36а йорт**

**Тел.: (84361) 29-435 факс: (84361) 29-435, эл.адрес: Urah.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**08.11.2021** **Уракчы авылы** **№ 2**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлегенең Урахча, Мельничный Починок авылларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районынын «Урахча авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 елның 18 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлеге Урахча, Николаевка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының үткәрүне билгеләргә.
2. 2021 елның 19 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлеге Мельничный Починок, Наратлы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча
3. Халык җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлеге составына керүче Уракчы, Мельничный Починок, Наратлы, Николаевка авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы»:

- авыл җирлеге чигендәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту өчен ;

- Уракчы авылы Яр буе урамы, Мельничный Починок авылы Давыдов һәм Елгаарьягы урамнары, Наратлы авылы Карбышева урамы юлларын ремонтлау өчен;

-трактор өчен өстәмә җиһазлар сатып алу;

- су белән тәэмин итү системаларын рәсмиләштерү өчен;

- авыл җирлеге чигендәге су белән тәэмин итү җайланмаларын тәртиптә тоту өчен (суэтем башняларына тирәнлек насослары сатып алу өчен);

- авыл җирлеге чикләрендә урамнарны яктырту һәм аларга хезмәт күрсәтү;

- Уракчы авылында балалар һәм спорт мәйданчыклары урнаштыру.

«ӘЙЕ» «ЮК».

5. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракча авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Уракча авылы, Совет урамы, 36а йорты, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Мельничный Починок авылы, Киров урамы, 20Б йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районының
Уракчы авыл җирлеге башлыгы Ф.М.Гараев